КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 9 ноябрь г.Казань № б-2473

Республика башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча эшен камилләштерү максатларында:

1. Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча ведомствоара эшче төркем төзергә.

2. Бу боерыкка теркәлгән Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәне һәм аның составын расларга.

3. Әлеге ведомствоара эшче төркемгә 30 көн эчендә 2025 елга кадәр чорга Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү чаралары планын эшләргә һәм расларга.

4. Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарына чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү чараларын гамәлгә ашыруда катнашуны тәкъдим итәргә.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Л.Р.Фазлыевага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 9 ноябрь, б-2473 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча ведомствоара эшче төркем турында нигезләмә

1. Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча ведомствоара эшче төркем (алга таба – эшче төркем) даими эшли торган киңәшләшү органы булып тора.

2. Эшче төркем үз эшчәнлегендә федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына, шул исәптән Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт илкүләм сәясәте стратегиясе турында» 2012 елның 19 декабрендәге 1666 номерлы Указы белән расланган 2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясе дәүләт илкүләм сәясәте стратегиясенә, Россия Федерациясе Президентының «2019 – 2025 елларга Россия Федерациясе дәүләт миграция сәясәте концепциясе турында» 2018 елның 31 октябрендәге 622 номерлы Указы белән расланган 2019 – 2025 елларга Россия Федерациясе дәүләт миграция сәясәте концепциясенә, Милләтләр эшләре федераль агентлыгының 2020 елның 17 ноябрендәге 142 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары өчен «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү һәм интеграцияләү турында» методик тәкъдимнамәләргә, Милләтләр эшләре федераль агентлыгының 2022 елның 29 декабрендәге 199 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары өчен Россия Федерациясе территориясендә чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру нәтиҗәлелеген арттыру буенча методик тәкъдимнамәләргә, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясен раслау турында» 2008 елның 3 июлендәге ПУ-312 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасында дәүләт милли сәясәте концепциясенә, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә.

3. Эшче төркемнең төп бурычлары:

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү мәсьәләләре буенча республика башкарма хакимият органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар эшчәнлеген координацияләү, аларның эшчәнлеге нәтиҗәлелеген арттыру буенча чаралар күрү;

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү өлкәсендә мәсьәләләрне оператив карап тикшерү, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр буенча советның Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләүнең актуаль мәсьәләләре буенча утырышларында карау өчен тәкъдимнәр әзерләү;

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү чаралары планын эшләү һәм раслау, аны гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны башкару.

4. Эшче төркем түбәндәгеләргә хокуклы:

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарыннан, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарыннан, иҗтимагый һәм дини берләшмәләрдән, фәнни һәм башка оешмалардан эшче төркем компетенциясенә кагылышлы мәсьәләләр буенча мәгълүмат соратып алырга;

республика башкарма хакимият органнарының һәм Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча эшен камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләргә;

Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр советына Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләүнең актуаль мәсьәләләрен карап тикшерү буенча тәкъдимнәр кертергә;

үз утырышларына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары, иҗтимагый һәм дини берләшмәләр, фәнни һәм башка оешмалар вәкилләрен чакырырга.

5. Эшче төркем аның рәисе, өч рәис урынбасары, секретаре һәм әгъзалары составында төзелә.

6. Эшче төркем утырышларын эшче төркеме рәисе, ә ул булмаганда эшче төркем рәисе урынбасарларының берсе уздыра. Эшче төркем утырышлары кирәк булуга карап, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышның көн тәртибе, аны уздыру датасы һәм тәртибе эшче төркем рәисе тарафыннан билгеләнә.

Эшче төркем утырышларын әзерләүне һәм уздыруны эшче төркем секретаре гамәлгә ашыра.

7. Эшче төркем әгъзаларына, утырыш үткәрү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, аның турында хәбәр ителә.

8. Эшче төркем утырышлары, әгәр алар эшендә эшче төркем составының яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы була. Утырышта эшче төркем әгъзасы булмаган очракта, ул карап тикшерелә торган мәсьәләләр буенча үз фикерен язма рәвештә бирергә хокуклы.

9. Эшче төркем карарлары күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәлиткеч була.

10. Эшче төркемнең карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа эшче төркем секретаре кулын куя, утырышта рәислек итүче тарафыннан раслана һәм эшче төркем әгъзаларына җибәрелә.

_______________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 9 ноябрь, б-2473 нче
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасында чит ил гражданнарын социаль һәм мәдәни адаптацияләү буенча ведомствоара эшче төркем составы

| | |
|---|---|
| Фазлыева Ләйлә Ринат кызы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, эшче төркем рәисе |
| Натфуллин Дамир Данил улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары |
| Таҗетдинова Клара Алексеевна | Татарстан Республикасы хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары |
| Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы, эшче төркем секретаре |

Эшче төркем әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Арсланов Азат Мөхәммәтгали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсе башлыгы урынбасары |
| Бәдриев Илдар Фоат улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы |
| Барышев Александр Георгиевич | «Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе башкарма секретаре (килешү буенча) |
| Выборнов Андрей Андреевич | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының югары, урта һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге башлыгы |

| | |
|---|---|
| Габдрахманова Гөлнара Фаат кызы | «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты» дәүләт бюджет учреждениесенең этнология бүлеге мөдире |
| Галиев Марат Шәүкәт улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Миграция мәсьәләләре идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гафаров Марат Рөстәм улы | Татарстан Республикасының Һөнәр берлекләре федерациясе рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Гыймаев Илшат Сәхап улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Кадыйров Тимур Рәфкать улы | «Татарстан халыкларының Дуслык йорты» дәүләт бюджет учреждениесе директоры, «Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче халыклар вәкилләре ассамблеясе каршындагы Татарстан халыкларының Яшьләр ассамблеясе» төбәк яшьләр иҗтимагый оешмасы советы рәисе |
| Лернер Герман Янович | Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры урынбасары |
| Мәхмүтов Марсель Азат улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары |
| Мостафин Данил Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре департаментына караган Милли сәясәтне гамәлгә ашыру идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Мостафина Софья Альфред кызы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре министрның беренче урынбасары |
| Нугуманова Людмила Николаевна | өстәмә һөнәри белем бирүче «Татарстан Республикасының Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Патеев Ринат Фаикъ улы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының этникара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне гармонизацияләү комиссиясе рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Пахомов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасының Предприятиеләр һәм сәнәгатьчеләр ассоциациясе (эш бирүчеләр төбәк берләшмәсе) генераль директоры (килешү буенча) |
| Сабурская Сария Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Сәлимгәрәев Айдар Сәетгәрәй улы | Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Сафин Ленар Ринат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры (килешү буенча) |
| Таишева Лилия Әхәт кызы | «Яңа гасыр» автоном хәйрия коммерциягә карамаган оешмасы генераль директоры (килешү буенча) |
| Титова Татьяна Алексеевна | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирү федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең Халыкара мөнәсәбәтләр институтына караган Тарих фәннәре һәм бөтендөнья мәдәни мирасы югары мәктәбенең антропология һәм этнография кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Яковлев Константин Геннадиевич | Татарстан халыклары ассамблеясе Советы рәисе урынбасары – Татарстан халыклары ассамблеясе Советының башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча). |

---